КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 апрель г.Казань № 271

Алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссиясен төзү турында

«Россия Федерациясендә алга китеп социаль-икътисадый үстерү территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә алга китеп социаль-икътисадый үстерү территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче, «Чаллы» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясен төзү турында» 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче, «Түбән Кама» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясен төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1609 нчы, «Чистай» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясен төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1610 нчы, «Зеленодольск» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясен төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1611 нче карарлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофиль-ле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территория-сендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 04 февраль, 61 нче карары нигезендә КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне төзергә:

«Чаллы» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссиясен;

«Түбән Кама» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссиясен;

«Чистай» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссиясен;

«Зеленодольск» алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссиясен.

2. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга китеп социаль-икътисадый үстерү территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү комиссиясе турында нигезләмәне;

әлеге карарның 1 пункты нигезендә төзелгән комиссияләр составлары.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия төзү хакында» 2016 ел, 16 апрель, 235 нче карары белән расланган «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссиясенә үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 31 октябрь, 801 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия төзү хакында» 2016 ел, 16 апрель, 235 нче карары белән расланган «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссиясенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 02 июнь, 330 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел 30 декабрь, 1137 нче карарының 3 пункты.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин